КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 ноябрь г.Казань № 1064

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 26 июнь, 516 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 26 июнь, 516 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибенең 2 нче пунктында «50 яшькә кадәрге» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибенең 2 нче пунктында «50 яшькә кадәрге» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин